**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2334**
**20.05.2020**

Күчемсез милеккә карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына карата төзелгән җир участокларын арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен кичектереп тору шартлары турында

«Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында аеруча зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күчемсез милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләү шартларына һәм срокларына таләпләр билгеләү турында» 2020 елның 3 апрелендәге 439 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге күчемсез милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартлары турында» 2020 елның 22 апрелендәге 314 номерлы карары, шәһәр Хакименең «Яңа коронавирус инфекциясе таралуга, нефтькә бәяләрнең һәм доллар курсының волатильлегенә бәйле хәлнең начарлануы шартларында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча штабны һәм чаралар планын раслау турында» 2020 елның 21 мартындагы М 103 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Күчемсез милеккә карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына карата төзелгән җир участокларын арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен кичектереп тору шартларын 1 нче кушымтада каралганча расларга.

2. Түбәндәгеләргә өстәмә килешүнең үрнәк формаларын расларга:

- күчемсез милеккә карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәсенә, 2 нче кушымтада каралганча;

- Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участогына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участогына карата төзелгән җир участогын арендалау шартнамәсенә, 3 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru), шәһәрнең рәсми сайтында (www.nabchelny.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 20 маендагы
2334 номерлы карарына
1 нче кушымта

Күчемсез милеккә карата төзелгән
муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча,
Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына һәм дәүләт милке
чикләнмәгән җир участокларына карата төзелгән җир участокларын арендалау
шартнамәләре буенча аренда түләүләрен кичектереп тору
шартлары

1. Күчемсез милек объектларыннан файдаланган өчен 2020 елда каралган аренда түләвен түләүне кичектереп торуның әлеге шартлары, исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары белән расланган яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында аеруча зыян күргән Россия икътисады тармакларында эшчәнлек алып баручы оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр булып торган муниципаль күчемсез милек арендаторлары белән төзелгән муниципаль мөлкәтне (торак урыннардан тыш) арендалау шартнамәләре һәм җир участокларын арендалау шартнамәләре (алга таба – аренда шартнамәсе) буенча, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы нигезендә 2020 елда Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертү турында карар кабул ителгәнче бирелгән.

2. Кичектереп тору мөмкинлеге муниципаль милектәге күчемсез милек объектларына, муниципаль милектәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына карата бирелә.

3. Кичектереп тору мөмкинлеге Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датадан башлап 2020 елның 1 октябренә кадәр түбәндәге шартларда бирелә:

1) кичектереп тору мөмкинлеге бирелә торган аренда түләүләренең суммасы, 2021 елның 1 гыйнварыннан башлап 2023 елның 1 гыйнварыннан соңга калмыйча, аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысы күләменнән артмаган күләмдәге тигез түләүләр белән айга бер тапкырдан да еш булмаган этапларга бүлеп түләнергә тиеш.

2) кичектереп тору мөмкинлеге Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булу срогына тиешле чор өчен аренда түләве күләмендә һәм Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимының гамәлдә булуы туктатылган көннән башлап 2020 елның 1 октябренә кадәр тиешле чор өчен аренда түләвенең 50 проценты күләмендә бирелә;

3) кичектереп тору мөмкинлеге бирелү сәбәпле, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле (шул исәптән мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) башка җаваплылык чаралары кулланылмый;

4) кичектереп тору сәбәпле, арендага бирүче тарафыннан арендатор түләргә тиешле өстәмә түләүләрне билгеләү рөхсәт ителми;

5) кичектереп тору мөмкинлеге бирелә торган аренда түләвенең күләме яклар килешүе буенча киметелә;

6) Бердәм дәүләт юридик затлар реестры яисә Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестры белешмәләре нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага арендатор тарафыннан яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында аеруча зыян күргән Россия икътисады тармакларында эшчәнлек гамәлгә ашыру;

7) әгәр аренда шартнамәсендә арендатор тарафыннан коммуналь хезмәтләрдән файдаланган өчен түләүләрне һәм (яки) арендалана торган мөлкәтне карап тоту чыгымнарын аренда түләвенә кертү каралган булса, аренда түләвенең күрсәтелгән өлеше буенча кичектереп тору мөмкинлеге бирелми, Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булу чорында арендага бирүче мондый хезмәтләр өчен түләүдән һәм (яки) мондый чыгымнар тотудан азат ителгән очраклардан тыш.

4. Кичектереп тору шартлары, мондый килешү төзү датасына бәйсез рәвештә, кичектереп тору турында аренда шартнамәсенә өстәмә килешүгә карата кулланыла.

5. Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе:

1) арендатор мөрәҗәгать иткән көннән башлап 10 календарь көн эчендә, аренда шартнамәсе буенча аренда түләүләрен түләүне кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешү проектын Башкарма комитетының финанс идарәсе, хокук идарәсе белән килештерүне һәм әлеге проектны арендага бирүченең вәкиле тарафыннан имзалауны тәэмин итә;

2) аренда шартнамәсе буенча аренда түләвен түләүне кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешү проекты арендага бирүче тарафыннан имзаланган көннән башлап дүрт календарь көн эчендә, имзалау өчен өстәмә килешү проектын гариза бирүчегә җибәрә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2020 елның 20 маендагы
2334 номерлы карарына
2 нче кушымта

2020 елда күздә тотылган аренда түләвен кичектереп тору
һәм аны 2021-2022 елларда түләү шартлары турында
________ елның №____ аренда шартнамәсенә
№_____ өстәмә килешү

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе, алга таба «Милекче» дип аталучы, Нигезләмә һәм __________ елның № _____ ышаныч язуы нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты исеменнән эш итүче Башкарма комитетының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе башлыгы ______________________ исеменнән, «Арендага бирүче» дип аталучы, ___________________________ нигезендә эш итүче ________________________________ исеменнән һәм ___________________________, «Арендатор» дип аталучы, ___________________________ нигезендә эш итүче ________________________________ исеменнән, бергә «Яклар» дип аталучылар, түбәндәгеләр турында әлеге өстәмә килешүне төзеделәр:

1. Яклар, ________ елның №__ __ аренда шартнамәсенең (алга таба – Шартнамә) гамәлдә булуы кысаларында, ___________________________ нигезендә (норматив хокукый акт реквизитлары), Арендаторга Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датадан башлап (19.03.2020 елдан башлап) 01.10.2020 елга кадәр срокка түбәндәге шартларда аренда түләвен түләүне кичектереп тору мөмкинлеге бирелү турында килештеләр:

- 19.03.2020 елдан башлап Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы тәмамланган датага кадәр чорда түләү каралган айлык аренда түләве 100 прцент күләмендә;

- Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы тәмамланган датадан башлап 01.10.2020 елга кадәр чорда түләү каралган айлык аренда түләве (алга таба – кичектерелгән аренда түләве) Арендатор тарафыннан Шартнамәгә әлеге өстәмә килешүнең 2 пунктында билгеләнгән тәртиптә 01.01.2021 елдан башлап һәм 01.01.2023 елдан соңга калмыйча түләнә;

2. Кичектерелгән аренда түләве Арендатор тарафыннан 20___ елның _______ башлап хисап аеның соңгы числосыннан соңга калмыйча, акчаларны _______ (_____) сум күләмендә бертигез түләүләр белән (2020-2022 елларда Шартнамәнең гамәлдә булу срогына бәйле рәвештә) ____________ исәп-хисап счетына күчерү юлы белән, 2021-2022 елларда түләнә (түләүләр графигы нигезендә).

Кичектерелгән аренда түләвен түләү күләме Шартнамә буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан арта алмый.

3. Шартнамә буенча, 2021-2022 елларда түләнергә тиешле айлык аренда түләве Шартнамәдә каралган срокларда Арендатор тарафыннан аерым түләүләр белән түләнә.

4. Арендатор кичектерелгән аренда түләвенең калган өлешен ________________ исәп-хисап счетына срогыннан алда күчерергә яки акчаларны кичектерелгән аренда түләвенең аннан соңгы түләүләре исәбенә кертергә хокуклы.

5. Кичектереп тору сәбәпле 19.03.2020 елдан 01.10.2020 елга кадәрге чорда, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки Арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле, шул исәптән аренда шартнамәсендә каралган җаваплылык чаралары кулланылмый.

6. Шартнамәне срогыннан алда өзгәндә, Арендатор 2020 елда мөлкәттән фактта файдалану срогы өчен кичектерелгән аренда түләвен, Шартнамәне өзгән датадан башлап биш календарь көн эчендә, берьюлы тулы күләмдә Арендага бирүчегә түли.

7. Шартнамәнең башка шартлары үзгәрешсез кала.

8. Әлеге өстәмә килешү бер үк төрле юридик көчкә ия булган ______ нөсхәдә төзелде.

9. Әлеге өстәмә килешү Яклар тарафыннан имзаланган вакыттан башлап үз көченә керә һәм ___________ елның № _________ Шартнамәнең аерылгысыз өлеше булып тора.

9[1] Әлеге өстәмә килешү хокукларны теркәү органында дәүләт теркәвенә алынган вакыттан башлап үз көченә керә һәм ___________ елның № _________ Шартнамәнең аерылгысыз өлеше булып тора.

ЯКЛАРНЫҢ ИМЗАЛАРЫ:

| «Арендатор» | «Арендага бирүче» |
|---|---|
| ___________________________________ | «Яр Чаллы шәһәре |
| телефон: ___________________________ | муниципаль берәмлеге |
| Адрес: _____________________________ | Башкарма комитеты» МКУ |
| Исәп-хисап/счеты ___________________ | 423805, Яр Чаллы шәһәре, |
| Банк _______________________________ | Х. Туфан проспекты, 23 йорт |
| ИНН ____________, БИК ____________, | ИНН ____________, БИК ____________, |
| ОГРН ______________, КПП _________ | ОГРН ______________, КПП _________ |
| Җитәкче | Яр Чаллы шәһәре МБ Башкарма комитетының җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы |
| __________________ _______________ | __________________________ |
| имза м.у. | м.у. |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

---

[1] Шартнамә бер елга яки аннан күбрәк срокка төзелгән очракта кертелә.

Башкарма комитетның
2020 елның 20 маендагы
2334 номерлы карарына
3 нче кушымта

2020 елда күздә тотылган аренда түләвен кичектереп тору
һәм аны 2021-2022 елларда түләү шартлары турында
________ елның №____ аренда шартнамәсенә
№_____ өстәмә килешү

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе, шәһәр Уставы нигезендә эш итүче Башкарма Җитәкчесе Салахов Фәрид Шавкат улы исеменнән, алга таба «Арендага бирүче» дип аталучы, бер яктан, һәм ___________________________, «Арендатор» дип аталучы, _________________________ нигезендә эш итүче ______________________________ исеменнән, бергә «Яклар» дип аталучылар, түбәндәгеләр турында әлеге өстәмә килешүне төзеделәр:

1. Яклар, ________ елның №____ аренда шартнамәсенең (алга таба – Шартнамә) гамәлдә булуы кысаларында, ___________________________ нигезендә (норматив хокукый акт реквизитлары), Арендаторга Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датадан башлап (19.03.2020 елдан башлап) 01.10.2020 елга кадәр срокка түбәндәге шартларда аренда түләвен түләүне кичектереп тору мөмкинлеге бирелү турында килештеләр:

- 19.03.2020 елдан башлап Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы тәмамланган датага кадәр чорда түләү каралган айлык аренда түләве 100 прцент күләмендә;

- Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы тәмамланган датадан башлап 01.10.2020 елга кадәр чорда түләү каралган айлык аренда түләве (алга таба – кичектерелгән аренда түләве) Арендатор тарафыннан Шартнамәгә әлеге өстәмә килешүнең 2 пунктында билгеләнгән тәртиптә 01.01.2021 елдан башлап һәм 01.01.2023 елдан соңга калмыйча түләнә;

2. Кичектерелгән аренда түләве Арендатор тарафыннан 20___ елның _______ башлап хисап аеның соңгы числосыннан соңга калмыйча, акчаларны _______ (_____) сум күләмендә бертигез түләүләр белән (2020-2022 елларда Шартнамәнең гамәлдә булу срогына бәйле рәвештә) ____________ исәп-хисап счетына күчерү юлы белән, 2021-2022 елларда түләнә (түләүләр графигы нигезендә).

Кичектерелгән аренда түләвен түләү күләме Шартнамә буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан арта алмый.

3. Килешү буенча, 2021-2022 елларда түләнергә тиешле айлык аренда түләве Килешүдә каралган срокларда Арендатор тарафыннан аерым түләүләр белән түләнә.

4. Арендатор кичектерелгән аренда түләвенең калган өлешен ________________ исәп-хисап счетына срогыннан алда күчерергә яки акчаларны кичектерелгән аренда түләвенең аннан соңгы түләүләре исәбенә кертергә хокуклы.

5. Кичектереп тору сәбәпле 19.03.2020 елдан 01.10.2020 елга кадәрге чорда, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки Арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле, шул исәптән аренда шартнамәсендә каралган җаваплылык чаралары кулланылмый.

6. Шартнамәне срогыннан алда өзгәндә, Арендатор 2020 елда мөлкәттән фактта файдалану срогы өчен кичектерелгән аренда түләвен, Шартнамәне өзгән датадан башлап биш календарь көн эчендә, берьюлы тулы күләмдә Арендага бирүчегә түли.

7. Шартнамәнең башка шартлары үзгәрешсез кала.

8. Әлеге өстәмә килешү бер үк төрле юридик көчкә ия булган ______ нөсхәдә төзелде.

9. Әлеге өстәмә килешү Яклар тарафыннан имзаланган вакыттан башлап үз көченә керә һәм ___________ елның № _________ Шартнамәнең аерылгысыз өлеше булып тора.

9[2] Әлеге өстәмә килешү хокукларны теркәү органында дәүләт теркәвенә алынган вакыттан башлап үз көченә керә һәм ___________ елның № _________ Шартнамәнең аерылгысыз өлеше булып тора.

ЯКЛАРНЫҢ ИМЗАЛАРЫ:

«Арендатор»
____________________________________
телефон: ____________________________
Адрес: ______________________________
Исәп-хисап/счеты ___________________
Банк _______________________________
ИНН ____________, БИК ____________,
ОГРН ______________, КПП _________

Җитәкче

___________________ ________________
м.у.

«Арендага бирүче»
«Яр Чаллы шәһәре
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты» МКУ
423805, Яр Чаллы шәһәре,
Х. Туфан проспекты, 23 йорт

Башкарма комитет
Җитәкчесе

______________________ ___________
м.у.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова

---

[2] Шартнамә бер елга яки аннан күбрәк срокка төзелгән очракта кертелә.